СТАРОАЙМАНОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
село Старое Айманово,
ул.Новая, дом5А 423739

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Иске Айман авылы, Яна ур, 5А
йорт 423739

Тел/факс (885552)5-01-63
Saym.Akt@yandex.ru

КАРАР №13 | ПОСТАНОВЛЕНИЕ 05.06.2019ел

2019 елгы су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге  ачык сулыкларда коенуны тыю турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының “Иске Айман авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 03.06.2019 ел, №ПР-125 санлы карары белән, Иске Айман авыл җирлеге территориясендә пляжлар һәм суда массакүләм ял итү урыннары булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Башкарма комитеты, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елгы су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге  ачык сулыкларда коенуны тыярга.

2. Су коену сезоны дәвамында җирлек территориясендә ачык сулыкларда коенуны тыю турында халык белән аңлату эшләре  һәм балаларны махсус контрольдә тоту кирәклеге турында белешмәлекләр өләшеп аңлату эшләре алып барырга;

3. Балаларны караучысыз тоту һәм өлкән кешеләр тарафыннан контрольдә тоту рөхсәт ителгән гаиләләрне аерым контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән шәхси профилактик эш алып барырга, ата-аналарга кул куйдырып коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга;

4. Ачык сулыкларда су коенуны тыю турында аншлаглар урнаштырырга;

5. Әлеге карарны  Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында “ Иске Айман авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

6. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Айман авыл җирлеге
башкарма комитеты
җитәкчесе
М.Р.Ахметханов